ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $4^2$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«$4^2$. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән критерийларга туры килә торган күпфатирлы йортларны сүтү яисә реконструкцияләү каралган торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территориядә урнашкан күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәр түләүдән күрсәтелгән милекчеләрне әлеге карар нигезендә күчерә башлау каралган елның беренче аеннан башлап, әгәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән иртәрәк вакыт билгеләнмәгән булса, азат ителә. Бу вакытта торак урыннар милекчеләре тарафыннан элек кертелгән капиталь ремонт өчен кертемнәр торак төзелеше территориясен комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру максатларында кулланыла. Әгәр күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре капиталь ремонт фондын булдыру алымы итеп аны махсус счетта булдыруны сайлаган булсалар, әлеге өлештә күрсәтелгән күпфатирлы йорттагы барлык урыннарга милек хокукы дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә йә торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат милкенә күчкәннән соң, махсус счет иясе махсус счетка хокукны Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасына яисә муниципаль берәмлеккә тапшыра.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 05 апрель
№ 16-ТРЗ